# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МӘМӘШИР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
# КАРАР

«12 сентябрь, 2024 № 28

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында Нигезләмәсе хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 23, 26 статьялары, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында кодексы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мәмәшир авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында Нигезләмәсен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702

Мәмәшир авыл җирлеге Советы 12.09.2024 ел
28 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында Нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган түләү, Тәртип) тәртибе турында әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 23, 26 статьялары, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муницщипаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында, муниципаль органнарында (алга таба – җирле үзидарә органы) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән муниципаль хезмәткәрләр 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 28 статьясында (алга таба – Кодекс) билгеләнгән шартларда тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә хокуклы.

3. Әлеге Тәртип максатларында тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәч, яки картлык буенча вакытыннан алда иминият пенсиясен яки инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләгәндә һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда муниципаль хезмәттән (алга таба - муниципаль хезмәт) итү аңлашыла.

4. Муниципаль хезмәттән киткәндә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле, муниципаль хезмәткәргә әлеге Нигезләмә нигезендә билгеләнә торган күләмдә бер тапкыр бирелә торган акча (поощрение) түләнә.

Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат иткән көнгә билгеләнә.

5. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәттән азат ителгәндә муниципаль хезмәткәргә эштән азат ителгән көнгә биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча аның айлык акчалата кереме биш тапкыр арттырылган күләмдә, муниципаль хезмәт стажы 15 ел булганда һәм муниципаль хезмәтнең һәр тулы елы өчен – өстәмә 0,5 акчалата кереме кадәр, әмма муниципаль хезмәткәрнең акчалата кереме ун размердан да артмаган бер мәртәбә бирелә торган түләү түләнә.

6. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турындагы карар җирле үзидарә органы җитәкчесе – яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан кабул ителә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү турында җирле үзидарә органы карары кабул ителү белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

7. Бер мәртәбә түләү күләмен билгеләү өчен, җирле үзидарә органы Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына түбәндәге документларны тапшыра:

вазыйфаи окладны, класслы чины өчен айлык өстәмәне һәм муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәне расшифровкалап, муниципаль хезмәткәрне айлык акчалата тәэмин итү турында белешмә.

муниципаль хезмәттәге эш стажы турында җитәкче раслаган белешмә;

бер тапкыр бирелә торган түләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган классны чин бирү, муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата кереме составына керә торган вазыйфаи окладка өстәмәләр билгеләү турында күрсәтмәләрдән өземтә;

8. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата керем составына кертелә:

- вазыйфаи оклад;
- классны чин өчен айлык өстәмә түләү;
- муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә.

9. Җирле үзидарә органы документларны әлеге Нигезләмәнең 8 пункты нигезендә муниципаль хезмәткәр тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле эштән азат ителгән көнгә кадәр 30 календарь көн кала тапшыра.

10. Мәмәшир авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертелгәннән соң, Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җыелма бюджет язмасына һәм бюджет йөкләмәләре лимитларына үзгәрешләр билгеләнгән тәртиптә расланган көннән алып өч эш көне эчендә җирле үзидарә органының бюджет акчаларын баш бүлүчесенә, муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган түләү түләү өчен, бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәрнамә җиткерә.

11. Җирле үзидарә органы күрсәтелгән хәбәрнамәләр нигезендә муниципаль хезмәткәргә бер мәртәбә бирелә торган түләү түли.

12. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү бер тапкыр түләнә. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыккач һәм аннан соң муниципаль хезмәт туктатылгач, гражданин муниципаль хезмәткә кергәндә әлеге Тәртиптә билгеләнгән бер тапкыр бирелә торган түләү кабат түләнми.